РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА И ГОРОДА НУРЛАТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҺӘМ НУРЛАТ ШӘҺӘРЕ БАШЛЫГЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 121 «01» 09 20 26 г.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 - 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нурлат муниципаль районы Советының 2021 елның 13 мартындагы 53 номерлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны үткәрүне оештыручы итеп Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген билгеләргә тәкъдим итәргә.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1 гавами тыңлаулар үткәрү вакыты – 2026 елның 21 сентябрендән сәгать 10.00да;

3.2. үткәрү срогы-әлеге карар басылып чыккан көннән алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр кимендә бер ай һәм өч айдан да артмаган;

3.3. үткәрү урыны-ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының кече залы, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: ТР, Нурлат ш., Совет ур., 117 йорт.

3.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган, чыгыш ясау хокукы булган гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Татарстан Республикасы, Нурлат ш.,

Совет ур., 117 йорт (архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге), эш көннәрендә-8.00 дән 17.00 гә кадәр;

3.5. чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты-2026 елның 15 сентябренә кадәр (тел.3-19-09).

4. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегендә халык тыңлауларына чыгарыла торган мәсьәлә буенча экспозиция оештырырга, физик һәм юридик затлардан тәкъдимнәр, киңәшләр һәм гаризалар кабул итәргә, адресы: Татарстан Республикасы, Нурлат ш., Совет ур., 117 й.

5. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында https://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Район Башлыгы Д.А. Ишкинеев